ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**РАСПОРЯЖЕНИЕ**
**09.11.2018**

Зеленодольск
шәһәре

**БОЕРЫК**
**№ 03-04-74**

Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының контракт хезмәтен төзү турында

2013 елның 05 апрелендәге «Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алулар өлкәсендә контракт системасы турында» 44-ФЗ номерлы Федераль законның 38 статьясы нигезендә, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты ихтыяҗларын тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алу өлкәсендә контракт хезмәте составын төзергә һәм расларга (Боерыкка 1 нче кушымта).
2. Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты ихтыяҗларын тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләрне сатып алулар өлкәсендә контракт хезмәте турындагы нигезләмәне (Боерыкка 2 нче кушымта) расларга.
3. Түбәндәге карарлар үз көчләрен югалткан дип танырга:

- Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2014 елның 26 мартындагы ОД-11 номерлы боерыгы;
- Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2014 елның 26 мартындагы ОД-88 номерлы боерыгы;
- Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2016 елның 29 октябрендәге 60-60 номерлы боерыгы.

2. Әлеге боерыкның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче Д.А. Сапожников

Зеленодольск муниципаль районы
Башкарма комитеты
боерыгына 1 нче кушымта

Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты ихтыяҗларын тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алу өлкәсендә контракт хезмәте составы

1. Контракт хезмәте җитәкчесе - Мөхәммәтханов Тимур Фәрит улы, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының бухгалтерлык исәбе һәм хисаплылык бүлеге башлыгы;
2. Контракт хезмәте җитәкчесе урынбасары, контракт хезмәте хезмәткәре (Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты аппараты ихтыяҗлары өчен эчке сатып алулар буенча) - Овченкова Людмила Александровна, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының бухгалтерлык исәбе һәм хисаплылык бүлеге башлыгы урынбасары;
3. Контракт хезмәте хезмәткәре (төзелеш, инфраструктура, экология өлкәсендә сатып алулар буенча) - Котельников Роман Олегович, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары (төзелеш, инфраструктура һәм экология);
4. Контракт хезмәте хезмәткәре (мәгариф өлкәсендә сатып алулар буенча) - Афанасьева Рәисә Вәли кызы, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары (мәгариф һәм балигъ булмаганнар белән эш мәсьәләләре);
5. Контракт хезмәте хезмәткәре (торак сәясәте өлкәсендә сатып алулар буенча) - Матвеева Ольга Александровна, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары (гражданнарны авария хәлендәге торактан күчерү программасын гамәлгә ашыру);
6. Контракт хезмәте хезмәткәре (икътисадый анализ өлкәсендә сатып алулар буенча) - Стерякова Анастасия Сергеевна, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының социаль-икътисадый фаразлау һәм анализ бүлеге башлыгы;
7. Контракт хезмәте хезмәткәре (төзекләндерү өлкәсендә сатып алулар буенча) - Алексеева Лилия Зөфәр кызы, «ТР ЗМР торак-коммуналь хуҗалык департаменты» МБУ белгече (килешү буенча).

Зеленодольск муниципаль районы
Башкарма комитеты боерыгына
2 нче кушымта

Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты ихтыяҗларын тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алулар өлкәсендә контракт хезмәте турында нигезләмә

## I. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты ихтыяҗларын тәэмин итү өчен товарларны, эшләрне, хезмәт күрсәтүләрне сатып алулар өлкәсендә контракт хезмәте турында әлеге нигезләмә (алга таба - Нигезләмә) дәүләт яисә муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алуларны гамәлгә ашырганда контракт хезмәтен төзү һәм эшләтү тәртибен, шул исәптән сатып алуларны планлаштыру этабында, тәэмин итүчеләрне (подрядчыларны, башкаручыларны) билгеләү, контрактларны төзү һәм үтәү тәртибен билгели.

1.2. Контракт хезмәте Зеленодольск муниципаль районының Башкарма комитеты (алга таба - Заказчы) тарафыннан Заказчының ихтыяҗларын тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәтләр сатып алуны (алга таба - сатып алу) тәэмин итү максатларында төзелә.

1.3. Контракт хезмәте үз эшчәнлегендә Россия Федерациясе Конституциясенә, граждан законнарына, Россия Федерациясенең бюджет законнарына, 2013 елның 5 апрелендәге 44-ФЗ номерлы “Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында” Федераль законга (алга таба - Закон), башка норматив хокукый актларга, шул исәптән әлеге Нигезләмәгә таяна.

1.4. Сатып алуны гамәлгә ашырганда контракт хезмәте эшчәнлеген оештыруның һәм аның эшчәнлегенең төп принциплары түбәндәгеләр:

профессионализм - сатып алулар өлкәсендә теоретик һәм практик белемнәргә һәм күнекмәләргә ия булган квалификацияле белгечләрне һөнәри нигездә үз эшчәнлекләрен гамәлгә ашыру максатларында җәлеп итү;

ачыклык һәм аңлаешлылык - дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны, шул исәптән сатып алуларны гамәлгә ашыру ысулларын һәм аларның нәтиҗәләрен тәэмин итүгә юнәлдерелгән контракт хезмәте тарафыннан башкарыла торган гамәлләр турындагы мәгълүматтан ирекле файдалану;

эффективлык һәм нәтиҗәлелек - дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итүнең күрсәтелгән нәтиҗәләренә ааеруча нәтиҗәле ирешүне тәэмин итә торган шартларда дәүләт контрактлары төзү.

1.5. Контракт хезмәте структурасы һәм саны Заказчы тарафыннан билгеләнә һәм раслана. Вазыйфага билгеләү һәм аны вазыйфасыннан азат итү бары тик Заказчы җитәкчесенең яисә аның вазыйфаларын башкаручы затның карары буенча гына рөхсәт ителә.

Контракт хезмәтен контракт хезмәте җитәкчесе җитәкли.

1.6. Контракт хезмәтенең вазыйфаи затлары сатып алулар өлкәсендә югары белемле яисә өстәмә һөнәри белемле булырга тиеш.

1.7. Контракт хезмәтенең вазыйфаи затлары, тәэмин итүчеләрне (подрядчыларны, башкаручыларны) билгеләү нәтиҗәләре белән шәхсән кызыксынган физик затлар, шулай ук сатып алулар өлкәсендә Законнар нигезендә турыдан-туры контрольне гамәлгә ашыручы контроль органнары затлары була алмый. Контракт хезмәте вазыйфаи затының тәэмин итүчеләрне (подрядчыларны, башкаручыларны) билгеләү нәтиҗәләрендә шәхси кызыксынуына китерергә мөмкин булган хәлләр барлыкка килгән очракта, мондый зат бу хакта Заказчыга контракт хезмәте составыннан үзен төшереп калдыру максатларында язма рәвештә хәбәр итәргә тиеш.

1.8. Контракт хезмәте составында әлеге Нигезләмәнең 1.7 пунктында күрсәтелгән затлар ачыкланган очракта, Заказчы әлеге вазыйфаи затларны үзләренең бурычларын үтәүдән кичекмәстән азат итәргә һәм аларны Закон һәм әлеге Нигезләмә таләпләренә туры килгән башка вазыйфаи затка йөкләргә тиеш.

## II. Контракт хезмәте функцияләре һәм вәкаләтләре

2.1. Контракт хезмәте (сатып алуларның беркетелгән өлкәсе өлешендә контракт хезмәте хезмәткәре) түбәндәге функцияләрне һәм вәкаләтләрне башкара:

2.1.1. Сатып алуларны планлаштырганда:

сатып алулар планын эшли;

кирәк булганда тәэмин итүчеләр (подрядчылар, башкаручылар) белән консультацияләр оештыра һәм дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтү буенча тиешле базарларында конкурентлы мохит торышын билгеләү, иң яхшы технологияләрне һәм башка карарларны билгеләү максатларында мондый консультацияләрдә катнаша;

сатып алулар планына кертү өчен үзгәрешләр әзерли;

сатып алулар планын раслауны оештыра;

сатып алулар өлкәсендә бердәм мәгълүмат системасында (алга таба - ЕИС) сатып алулар планын һәм аңа кертелгән үзгәрешләрне урнаштыру өчен вәкаләтле учреждениегә җибәрә;

план-график эшли;

план-графикка кертү өчен үзгәрешләр әзерли;

план-графикны раслауны оештыра;

«Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының муниципаль заказы дирекциясе» МКУга (алга таба - Вәкаләтле учреждение) ЕИСта план-графикны урнаштыру һәм аңа кертелгән үзгәрешләрне җибәрә;

Законда каралган очракларда товарны, эшне яисә хезмәт күрсәтүләрне сатып алу буенча мәҗбүри җәмәгать фикер алышуын оештыра;

товар сатып алу, эш яисә хезмәт күрсәтүләрнең мәҗбүри җәмәгать фикер алышуы нәтиҗәләре буенча сатып алулар планнарына, план-графикларга, сатып алулар турындагы документациягә үзгәрешләр кертә яисә сатып алуны гамәлдән чыгаруны оештыра;

контрактның башлангыч (максималь) бәясен билгели һәм нигезли;

сатып алуның техник өлешен формалаштыра.

2.1.2. Тәэмин итүчеләрне (башкаручыларны, подрядчыларны) билгеләгәндә:

сатып алулар турында мәгълүмат картасын һәм ЕИСта урнаштыру өчен контракт проектын әзерләүне, сатып алулар турындагы документациягә үзгәрешләр кертүне гамәлгә ашыра;

тәэмин итүчеләрне (подрядчыларны, башкаручыларны) ябык ысуллар белән билгеләүдә катнашырга чакырулар әзерли һәм җибәрә;

2.1.3. Контрактны төзегәндә, үтәгәндә, үзгәрткәндә, өзгәндә:

сатып алуларны гамәлгә ашыруны тәэмин итә;

төзелгән контракт (килешү) буенча ЕИСта урнаштыру өчен контракт төзү (үтәү, үзгәртү, өзү) турында документларның мәгълүматларын әзерләүне гамәлгә ашыра һәм үз вакытында (3 эш көне эчендә) Вәкаләтле учреждениегә хәбәр итә.

тәэмин итүчеләрне (подрядчыларны, башкаручыларны) билгеләү нәтиҗәләренә карата шикаять белдерү турындагы эшләрне карауда катнаша;

дәгъвалау эшен башкару өчен материаллар әзерли.

2.1.4. Зеленодольск муниципаль районы норматив-хокукый актлары һәм мәйданчык регламенты нигезендә «Биржевая площадка» ЭТП һәм «Котировочные сессии Электронного каталога продукции» ресурсларын кулланып сатып алу процедураларын гамәлгә ашыра.

2.2. Контракт хезмәте (сатып алуларның беркетелгән өлкәсе өлешендә контракт хезмәте хезмәткәре) Законда каралган башка вәкаләтләрне гамәлгә ашыра.

2.3. Әлеге Нигезләмәнең 2.1 пунктында күрсәтелгән функцияләрне һәм вәкаләтләрне гамәлгә ашыру максатларында контракт хезмәтенең вазыйфаи затлары түбәндәгеләргә бурычлы:

1) тәэмин итүчене (подрядчыны, башкаручыны) билгеләү процедураларын үткәрү барышында мәгълүм булган белешмәләрне, Россия Федерациясе законнарында турыдан-туры каралган очраклардан тыш, фаш итүгә юл куймаска;

2) вазифа бурычларын тиешенчә үтәү өчен кирәкле квалификация дәрәҗәсен саклау;

3) Россия Федерациясе законнарында турыдан-туры каралган очраклардан тыш, сатып алулар процедураларын тәэмин итүчене (подрядчыны, башкаручыны) билгеләүдә җиңүче ачыкланганчы, сатып алуларда катнашучылар белән сөйләшүләр алып бармаска;

4) кирәк булганда, үз эшенә экспертларны, эксперт оешмаларын Закон һәм башка норматив хокукый актларда каралган таләпләргә ярашлы рәвештә җәлеп итәргә;

5) Законда билгеләнгән башка йөкләмәләрне һәм таләпләрне үтәргә.

2.4. Закон нигезләмәләрендә каралган сатып алуларны үзәкләштергәндә, контракт хезмәте әлеге Нигезләмәнең 2.1-2.2 пунктларында каралган һәм тәэмин итүчеләрне (подрядчыларны, башкаручыларны) билгеләү вәкаләтләрен

гамәлгә ашыра торган тиешле Вәкаләтле органга, Вәкаләтле учреждениегә тапшырылмаган функцияләрне һәм вәкаләтләрне гамәлгә ашыра.

2.5. Контракт хезмәте җитәкчесе:

2.5.1. Контракт хезмәте хезмәткәрләре арасында вазыйфаларны бүлә;

2.5.2. Заказчы каравына контракт хезмәте хезмәткәрләрен вазыйфага билгеләү һәм вазыйфадан азат итү турындагы тәкъдимнәрне тапшыра;

2.5.3. Контракт хезмәте компетенциясе чикләрендә Заказчының башка структур бүлекчәләренең эшен координацияли;

2.5.4. Законда каралган башка вәкаләтләрне гамәлгә ашыра.

## III. Контракт хезмәте хезмәткәрләренең җаваплылыгы

3.1. Сатып алуда катнашучы һәркем, шулай ук җәмәгать контролен гамәлгә ашыручы иҗтимагый берләшмәләр, юридик зат берләшмәләре Россия Федерациясе законнары нигезендә суд тәртибендә яки закон нигезендә билгеләнгән тәртиптә сатып алулар өлкәсендә контроль органына контракт хезмәте вазыйфаи затларының, контракт идарәчесенең гамәлләре (гамәлсезлеге) шикаять итәргә хокуклы, әгәр мондый гамәлләр (гамәлсезлеге) сатып алуда катнашучының хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен боза икән.

3.2. Законны, законда каралган башка норматив хокукый актларны, шулай ук әлеге Нигезләмә нормаларын бозуда гаепле булган контракт хезмәте вазыйфаи затлары Россия Федерациясе законнары нигезендә дисциплинар, гражданлык-хокукый, административ, җинаять җаваплылыгына тартыла.